СОВЕТ
БАГАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

17.12.2021 ел Багай ав. № 18

Төзекләндерү өлкәсендә предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен һәм әлеге сорауны норматив-хокукый җайга салуны Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә төзекләндерү өлкәсендә предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен һәм әлеге сорауны норматив-хокукый җайга салуны тапшырырга.
2. Әлеге карарны карау өчен Кайбыч муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыру ел саен Багай авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Кузнецова